СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2025 г. Агрыз № 3-3

2026 елга Әгерҗе муниципаль районының
муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруны Фаразлау планын (программасын)
раслау турында

"Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" 21.12.2001 № 178-ФЗ Федераль законына, "Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алынган күчемсез милекне читләштерүнең (отчуждение) үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 22.07.2008 № 159-ФЗ Федераль законына туры китереп, Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елга Әгерҗе муниципаль районының күчемсез муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның кушымтада бирелә торган фаразлау планын (программасын) расларга .
2. Әгерҗе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2026 елга «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) федераль кануннар нигезендә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, вакытлы матбугат басмасында - «Татмедиа» ААҖ филиалының«Әгерҗе хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигать ресурслары һәм аграр мәсьәләләр буенча Даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы урынбасары
Совет Рәисе урынбасары И.И. Ямалиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советы
Карары белән расланган

«13» ноябрь 2025 №3-3

**2026 елга «Әгерҗе муниципаль районы»**
**муниципаль берәмлекнең муниципаль мөлкәтен**
**ХОСУСЫЙЛАШТЫРУНЫҢ ФАРАЗЛАУ ПЛАНЫ (ПРОГРАММАСЫ)**

## I бүлек. 2026 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның бурычлары

2026 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) (алга таба текст буенча – Хосусыйлаштыруның фаразлау планы) 21.12.2001 елгы 178-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында"гы Федераль законга, 22.07.2008 елгы 159-ФЗ номерлы "Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алынган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы Федераль законга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 24.06.2025 елгы 47-1 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" муниципаль казна учреждениесе турында"гы Нигезләмәсенә туры китереп эшләнгән.

Муниципаль мөлкәт белән идарә итүнең базар икътисады шартларында төзелә торган системасының бер өлеше буларак, 2026 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның төп бурычлары булып, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру исәбенә муниципаль милек структурасын оптимальләштерү, шулай ук «Хосусыйлаштыру турында»гы 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү (отчуждение) үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 159-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен гамәлгә ашыру тора.

2026 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып:
- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан район бюджетына салым булмаган керемнәр керүне тәэмин итү;
- бюджетның керем өлешен арттыру;
- мөлкәтне карап тотуга район бюджетыннан чыгымнарны кыскарту тора.

Хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге икътисадындагы структур үзгәрешләр көтелми, чөнки хосусыйлаштыруга тәкъдим ителгән торак булмаган

бинада, милекчесе үзгәргәндә, муниципаль берәмлектәге икътисади хәлгә сизелерлек йогынты ясарга сәләтле производство урнаштырылмый.;

Хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) нигезендә сатылырга планлаштырыла торган барлык объектларның бәясе базар бәяләвен уздыру юлы белән ачыкланырга тиеш.

2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган мөлкәт исемлегенә, муниципаль милек структурасын алга таба оптимальләштерүне исәпкә алып, мөлкәт өстәлергә мөмкин.

## II бүлек. Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2026 елда приватизация планлаштырыла торган муниципаль милке

| № | Муниципаль милек объектының исеме | Муниципаль милек объектының урнашкан урыны | Кадастр номеры (күчемсез милек булса) | Приватизацияләү ысулы | Гамәлгә ашыруның фаразланган вакыты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Торак булмаган бина, 1962 елда төзелгән, гомуми мәйданы 359,9 кв. м., кадастр номеры 16:01:220573:423 мәйданы 1482 кв. м. булган җир кишәрлегендә урнашкан, | ТР, Әгерҗе шәһәре, Завод урамы, 61Анчы йорт | 16:01:110301:517 | ачык аукцион | 2нче квартал | Максаты буенча файдаланылмый. |
| 2 | Ясле-бакча бинасы, 1984 елда төзелгән, гомуми мәйданы 687,3 кв. м. | ТР, Әгерҗе муниципаль районы, Исәнбай авылы, Совет урамы, 87нче йорт | 16:01:140101:105 | ачык аукцион | 3нче квартал | Максаты буенча файдаланылмый. |
| 3 | Ясле-бакчаның котельный бинасы, 1984 елда төзелгән, гомуми мәйданы 64 кв. м. | ТР, Әгерҗе муниципаль районы, Исәнбай авылы, Совет урамы, 87нче йорт | 16:01:140104:185 | ачык аукцион | 3нче квартал | Максаты буенча файдаланылмый. |
| 4 | Торак булмаган бина, 1972 елда төзелгән, мәйданы 117,8 кв. м., кадастр номеры 16:01:220523:240 мәйданы 227 кв. м. булган җир кишәрлегендә урнашкан, | ТР, Әгерҗе шәһәре, Крестьян урамы, 2нче йорт | 16:01:220523:239 | ачык аукцион | 1нче квартал | Максаты буенча файдаланылмый. |
| 5 | Автобус ПАЗ 32053, 2008 ел, идентификация номеры (VIN) X1M3205C080007796, модель, двигатель № 523400, 81018280, | ТР, Әгерҗе муниципаль районы, Салагыш авылы | - | ачык аукцион | 2нче квартал | Максаты буенча файдаланылмый. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | кузов № X1M3205C080007796, У242ОМ 116rus | | | | | |
| 6 | Бина (мәктәп) 1992 ел п., гомуми мәйданы 1188,2 кв. м., кадастр номеры 16:01:200101:73 мәйданы 11057 кв. м. булган җир кишәрлегендә урнашкан, | ТР, Әгерҗе муниципаль районы, Азево авылы, Совет урамы, д. 81нче йорт | 16:01:200101:194 | ачык аукцион | 1нче квартал | Максаты буенча файдаланылмый. |
| 7 | 1992 елда төзелгән, гомуми мәйданы 129 кв. м., шул исәптән 2017 елда техник яктан яңадан корылган, Ф250/200 н=6 м төтен торбасы, ике казаны RS-A-100, RS-A-60; 16:01:200101:81кадастр номерлы мәйданы 351 кв. м. булган җир кишәрлегендә урнашкан. казанның газ үткәргечләр җыелмасы һәм СГ-ТК-Д25, | ТР, Әгерҗе муниципаль районы, Азево авылы, Совет урамы, 85а нчы йорт | 16:01:200101:197 | ачык аукцион | 1нче квартал | Максаты буенча файдаланылмый. |
| 8 | 16:01:220231:912, 117 кв. м мәйданлы җир кишәрлегендә урнашкан 14,9 кв. м мәйданлы торак булмаган бина. | ТР, Әгерҗе шәһәре, К.Маркс урамы, Б-11А йорт | 16:01:220231:914 | ачык аукцион | 1нче квартал | Максаты буенча файдаланылмый. |
| 9 | Chevrolet Niva автомобиле, 212300-55, 2017 ел, идентификация номеры VIN X9L212300J0644562, модель, двигатель номеры 2123, 0883654, КУЗОВ no X9L212300J0644562, г/н а 917 MB 716 | ТР, Әгерҗе шәһәре, К.Маркс урамы, Б-20нче йорт | - | ачык аукцион | 1нче квартал | Максаты буенча файдаланылмый. |